# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Икътисадый реформалар үткәрү чорында республиканың башкарма-бүлү органнарының эшен оештыру турында**

Илдәге икътисадый һәм иҗтимагый-сәяси вәзгыятьнең катлаулылыгын, республика халык хуҗалыгына нәтиҗәле идарә итү өчен кичекмәслек чаралар кабул итүнең зарурлыгын, дәүләт дисциплинасын, хокук тәртибен ныгытуны һәм башкарма хакимият органнары эшчәнлегендә бердәмлекне тәэмин итүне исәпкә алып, Татарстан Совет Социалистик Республикасы Югары Советы КАРАР БИРӘ:

1. Республиканың икътисадый һәм иҗтимагый-сәяси тормышында тотрыклылыкны тәэмин итү максатларында Татарстан ССР Президентына Татарстан ССР Конституциясе һәм законнары нигезендә норматив рәвештәге әмерләр чыгару һәм милек мөнәсәбәтләре, республиканың халык хуҗалыгына идарә итүне оештыру, бюджет-финанс системасы, хезмәт хакы һәм бәяләр кую, хокук тәртибен ныгыту мәсьәләләренә кагылышлы йомышлар кушу хокукын бирергә.

2. "Татарстан ССР Министрлар кабинеты турында" Татарстан ССР Законын кабул иткәнче, Татарстан ССР Президентына, Татарстан ССР Югары Советы белән килешеп, ә сессияләр арасында - Татарстан ССР Югары Советы Президиумы белән килешеп, республика башкарма хакимияте югары органнарының дәүләт төзелмәләрен үзгәртеп кору һәм төзү хокукын бирергә.

3. Районнарда, шәһәрләрдә, шәһәр районнарында, тиешле башкарма органның җитәкчесе буларак, хакимият /администрация/ башлыгы урынын кертергә.

Хакимият башлыгы районда, шәһәрдә, шәһәр районында халык депутатларының тиешле Советы башкарма комитетының /органының/ тиңдәш алмаштыручысы булачак.

4. "Татарстан ССРда җирле үзидарә турында" Татарстан ССР Законын кабул иткәнче, Татарстан ССР Президентына, халык депутатларының тиешле Советлары белән киңәшеп, район, шәһәр хакимияте башлыкларын билгеләү һәм аларны үз теләге белән яисә халык депутатларының тиешле Советы тәкъдиме буенча вазыйфаларыннан азат итү хокукын бирергә.

5. Әлеге Закон кабул ителгән мизгеленнән гамәлгә керә һәм 1992 елның 31 декабрендә үз көчен югалта.

Татарстан ССР Президенты М.Шәймиев

Казан,
1991 елның 29 ноябре
№ 1321-XII